# «ТУКАЙ… АЧЫЛЫП БЕТМӘГӘН АЕРЫМ УТРАУ»

*Халиуллина Р. И.*


# «TUKAY… AN UNEXPLORED ISLAND UNTIL THE END»

*Khaliullina R. I.*

Биредә Казан шәһәре музей комплексы фондларын күздән кичереп, Тукай исеме белән бәйле музей предметларын барлау, алар белән таныштыру максаты күздә тотыла, кайберләренә исә киңрәк тукталып үтелер. Музейда Тукай, аның даирәсе һәм аңа кагылышлы сәхифәләргә бәйле материаллар җыю максатчан рәвештә алып барылмаса да, теге яки бу коллекцияләр аша, я булмаса, аерым тематика буенча күргәзмәләр оештырганда шактый гына ядкәрләр тупланган икән. Г. Тукайның 125 еллыгына багышланган күргәзмәгә фондларыбыздан 300 гә якын саклау берәмлеге файдалануыбыз моны ачык күрсәтеп тора. Аларның күпчелеген китаплар, фоторәсемнәр, документлар, кульъязмалар, почта открыткалары, шулай ук сынлы сәнгать, графика һәм скульптура әсәрләре тәшкил итә.

Г. Тукайны искә алу кичәләрен без һәр елны уздырабыз. Юбилей елларында исә әлеге әдәби-музыкаль кичәләребез бөек шагыйрь хөрмәтенә оештырылган зур гына күргәзмәләр фонында уза. Күргәзмәләрне үзебезнең Музей фондларындагы материалларга нигезләнеп оештырырга тырышабыз. Үзебез дигәнемдә сүз 1992 елдан башлап өч дистә елга якын «Казан» милли мәдәният үзәгендә эшләп килгән Милли мәдәният музее турында бара. Казан шәһәре башкарма комитетының 2020 ел 23 июль карары белән «Казан» милли мәдәният үзәге Казан шәһәре музей комплексы буларак үзгәртелде. Бүгенге көндә музеебызга бирелгән яңа бинада (Бауман урамы, 3) төзекләндерү эшләре әле башланмаган, музеебыз фондлары төргәкләнгән хәлдә. Шулай да, артык киң колачлы булмаса да, филиалларыбыздагы мәйданчыкларда эшебезне дәвам итәбез. 2021 елның 21 апрелендә бөек Тукайның тууына 135 ел тулуга багышланган «Тукай безнең белән» дип аталган әдәби-музыкаль кичә уздырдык, кичә өчен махсус Г. Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф һәм әнисе Бибимәмдүдә ягыннан булган нәсел шәҗәрәсен, Тукайга һәм аның туган-тумачасына багышланган зур альбом һ. б. документаль материалларны эченә алган күргәзмәдә тәкъдим ителде.

Шагыйрьнең тормышын, аның нәсел-нәсәбен озак еллар өйрәнгән педагог һәм журналист Зәкия Рәсүлева 1992 елда төзеп тәмамлаган әлеге шәҗәрәдә – барлыгы 148 кеше, Тукайның әнисе ягыннан – 10,




*Г.Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф һәм әнисе Бибимәмдүдә ягыннан шәҗәрәсе Төзүчесе – шагыйрьнең нәсел-нәсәбен озак еллар өйрәнүче педагог һәм журналист Зәкия Рәсүлева.1992 ел. Кәгазь, тушь. Родословная поэта Г.Тукая со стороны отца Мухамматгарифа и матери Бибимамдуды Составитель родословной – исследователь жизни и рода поэта, педагог и журналист З.Расулева. 1992 г. Бумага, тушь. Инв. № КП–15604*



*Яңа өйләнешкән Кадыйр Рәсүлев һәм Зәйтүнә Мәүлүдова XX гасыр башы. Троицк шәһәре. Новобрачные К.Расулев и З.Мавлюдова. Начало XX в. г. Троицк 13×10 см. Инв. № КП–14876*



*К.Замитов. Г.Тукай 1990–1992 еллар. Шамот. К.Замитов. Г.Тукай 1990–1992 гг. Шамот 140×45см.  Инв. № КП–10461*



*К.Җәмитов. Г.Тукай һәм Ф.Әмирхан 1990 ел. Шамот.*
*К.Замитов. Г.Тукай и Ф.Амирхан 1990 г. Шамот. 72×70×60 см. Инв. № КП–10803*



*Р.Килдебәков. Шигырь дәфтәреннән 1993 ел. Киндер, майлы буяу Р.Кильдебеков. Из поэтической тетради 1993 г. Холст, масло 175×145 см. Инв. № КП–13734*







*Г.Тукайның 125 еллыгына багышлап «Казан» милли мәдәният үзәгендә оештырылган күргәзмәдән күренешләр. 2011 ел. Фрагменты выставки, посвященной 125-летию со дня рождения Г.Тукая, организованной в НКЦ «Казань». 2011 г.*



*Г.Тукайның төрле елларда басылып чыккан китаплары. Книги Г.Тукая,  изданные в разные годы*



*Ә.Фәтхетдинов. Шүрәле тәрәзә янында. 1990 ел. Агач. А.Фатхутдинов. Шурале у окна. Дерево. 1990 г. 66×73 см. Инв. № КП–8502*



*Тукайны соңгы юлга озату 1913 ел. Казан. Фотооткрытка. Похороны татарского поэта Г.Тукая 1913 г. Казань. Фотооткрытка 13,1×8,7 см. Инв. № КП–12917/ 3*



*Р.Вахитов. Г.Тукай портреты 1986 ел. Киндер, майлы буяу. Р.Вахитов. Портрет Г.Тукая. 1986 г. Холст, масло*



*И.Әхмәдиев. Тукай турында сюита. 2009 ел. Киндер, майлы буяу. И.Ахмадеев. Сюита о Тукае 2009 г. Холст, масло*

әтисе ягыннан 9 буын кешеләренең исемнәре теркәлгән. Әлеге нәселнең безгә билгеле иң борынгы бабалары яшәгән чор XVII гасырга карый. Ул Тукай исеме белән бәйле музей предметлары арасында хаклы рәвештә иң кадерле ядкәрләрдән исәпләнә. Шагыйрьгә, аның тормышына кагылышлы альбомда исә Тукайның метрика язуы күчермәсе, әти-әнисенең фотосурәтләреннән башлап, әтисе һәм әнисе ягыннан булган, илебезнең төрле тарафларында яшәгән 100 дән артык туганының фоторәсемнәре һәм Тукай исеме белән бәйле башка мәгълүматлар туплап бирелгән. Әлеге ядкәрләр үз вакытында шагыйрь эзләрен өйрәнүнең күркәм бер үрнәге булып тора. Яңа өйләнешкән парлар – Зәйтүнә Мәүлүдова белән Кадыйр Рәсүлевнең 1914 елда төшкән гаҗәеп туй фотосын һәм башка кызыклы гына фоторәсемнәрне дә безгә Зәкия апа тапшырган иде.

Татар халкы борын-борыннан бер-берсе белән аралашып, туганлашып яшәгән. Үзләренең нәсел шәҗәрәсендә берничәшәр гасырны берләштергән һәм татар халкын агарту, аның тарихын, мәдәниятен үстерү белән шөгыльләнгән күп кенә татар зыялылары гаиләләре үзара туганлык җепләре белән дә бәйләнә. З. Рәсүлева теге яки бу мөнәсәбәттә Г. Тукай шәхесенә барып тоташкан 30 га якын нәселнең шәҗәрәсен дә барлаган. Һәрбер нәселнең үз чорына карата күренекле булган затлары саны – 130 дан артык. Алар арасында Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, Г. Баруди, М. Бигиев, Ш. Күлтәси, Г. Исхакый, С. һәм Һ. Максудилар, Ф. Әмирхан, М. Мозаффария, Ф. Аитова, Л. Хөсәения, С. Шакулова, Ә. Еники, Г. Бәширов, А. Расих, А. Монасыйпов, И. Шәмсетдинов, Г. Кайбицкая, С. Айдаров, М. Шәймиев һ.б. бик күп күренекле шәхесләребез бар. З. Рәсүлева безнең музейга тапшырган нәселләр бәйләнешен күрсәткән шәҗәрәләр дә шуны раслый. Мөгаен, татар милләтенең зыялылар үстергән тотрыклы катламы турында да сүз алып барырга мөмкиндер. 1996 елда, Тукайның тууына 110 ел тулуга багышлап, әдипнең төп нәсел агачы һәм әлеге шәҗәрәләр буенча «Казан» милли мәдәният үзәгендә «И мөкатдәс моңлы сазым» дигән зур күргәзмә һәм андагы күренекле кешеләрнең кайберләре белән очрашу да уздырылган иде (шәхсән үзем Зәкия Рәсүлеваның нәселләр бәйләнешен чагылдырган шәҗәрәләренең Тукай музеенда булу-булмавыннан хәбәрдар түгел, бәлки алар анда да бардыр. Ничек кенә булмасын, аларны шул килешме, тулыландырыпмы, ничек тә булса дөньяга чыгару хакында уйлыйсы бар әле). Бер үк вакытта алар шулкадәр күп мәгълүмат чыганагы булуы ягыннан да әһәмияткә ия.

Үз вакытында Сибгат ага Хәким: «Безнең халык Тукайсыз бер генә көн дә яшәми»,– дип әйткән иде. Чыннан да шулай. Тукай һәм аның иҗаты халык тормышыннан аерылгысыз яшәүләрен дәвам итәләр. Музей хезмәткәре буларак, экспедицияләргә, халык арасына чыкканда моңа күп тапкырлар инандым мин. Тукай шигырьләре күчереп алынган күңел дәфтәрләре, аңа багышлан-

ган шигъри юллар, истәлекләр еш очрады. Мәсәлән, Казанда Җәүдәт Айдаров аша кергән материаллар арасында Ишми ишан кызы Латыйфа Динмөхәммәтованың Коръәне белән бергә, Тукай шигырьләре дә урын алган «Күңел дәфтәре»нә тап булсак, Оренбургтагы сәфәребездән безгә Гөлсем апа Хәсәнованың (кыз фамилиясе Галимова) Тукайлы истәлекләре ияреп кайтты. Алар безгә төбәк тарихчысы, публицист, Оренбург татарлары милли-мәдәни тормышында аерым урын тоткан җәмәгать эшлеклесе Мәдинә апа Рәхимкулова коллекциясе аша килеп керде. Гомере буе укытучы булып эшләгән Гөлсем Хәсәнова истәлек язмасын, 1985 елның 25 октябрендә язып тәмамлап, «Казан утлары»на җибәрергә әзерләгән булган. Аны ул: «Минем уемча, Җаек шәһәрендә үзләренең идеалларын яклап, татар халкының халыкка хезмәт итмәккә, иске тормышка каршы сугышка күтәрелгән бу ике йолдызы көнетөне дигәндәй планнарын корып, нинди генә авырлыклар, кыенлыклар күрсәләр дә, үз теләкләренә ирешеп, матур әдәбиятка, сәнгатькә юлбашчылар булдылар»,– дип башлаган[1]. Сүз ике яшьтәш, ике Габдулла турында бара (Габдулла Тукаев һәм Габдулла Кариев).

Гөлсем Хәсәнова 1899 елда Җаекта туа, биш яшеннән абыстайда белем ала, укытучысы Мотыйгулла хәзрәтнең сеңлесе була, аңарда гарәп-фарсы теленә дә, русчага да өйрәнә. Ул Г. Кариев укыган мәдрәсәнең күршеләрендә генә булуын, Г. Тукайның Кариев янына килеп йөрүен, Гөлсем апаның әнисенә я берсе, я икенчесе кереп, бер кадак оннан токмач эшләтергә бирүләрен, я күлмәк тегәргә яисә юарга кертүләрен искә ала, Җаек шәһәренә Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская труппасы килүен, Кариевның Гөлсем апаның әтисенең җиңсез озын казакиен театр уйнарга алып торуын бәян итә. Шулай ук Г. Тукайның үзе эшләгән типографиядә аңа «Өммегөлсем бинт Мөхәммәтвәли Галимия» дип яздырып визитка ясатып бирүе, аны озак еллар кадерләп саклавы хакында бик җылы итеп искә ала.

«Мәһабәт күренешле буйчан ачык йөзле, гөлдерәп торган көр тавышлы Габдулла Карины әтием бик ярата. Алар белән очрашкан саен сөйләшә, "Коръән хафиз ул", дип аркасыннан кага. Беркөн әтием кич урамнан соң гына керде. Әниемнең: "Кая бик озак тордың?" – дип соравына: "Мәдрәсә капкасы янында Габдуллалар белән сөйләшеп утырдым. Әлеге Мотыйгулла мәдрәсәсеннән килә торган Габдулла әйтә: "Вәли агай! Берничә язган нәрсәләремне Казанга җибәргән идем, хатлар килә башлады. Миңа хатларны олы кешеләргә язгандай: "Хөрмәтле вә гыйззәтле Габдулла әфәнде җәнапләренә!" – дип язалар.– Уйлыйлар ахыры, бу шигырьләрне язучы күкрәк киереп, чәчрәп торган егеттер дип. Белмиләр монда яшүсмерләр кебек юка гына, тыйнак кына Габдулла икәнемне",– ди».

Ул вакыт кыз балалар өчен мәктәпләр юк. Кайда хәлфә, кайда мулла кызы я хатыны укыта. Язу өйрәтергә теләмиләр. Мин Мотыйгулла хәзрәт туганы Газизә Галимия мәктәбендә укыдым. Бу хатын заманасының Кайбычта үскән га-

лиме, төркичә, гарәп, фарсы китаплары укыган. Ул вакыт фанатик муллалар тарафыннан тыелган кызларга язу өйрәтү, ул өйрәтте. Хәтта рус әлифбасы белән дә таныштырды. Шул вакыт чыга торган журналлар, газеталар («Фикер», «Әлгасрелҗәдит») белән таныштырды.

Тукайның «Туган тел», «Пар ат», «Теләнче», «Уян, татар» һ. б. шигырьләрен укыганда үзе дә бик кызыгып безнең белән хорга катышып китә иде. Матур әдәбиятка, шигырьләргә юл ачты, шуңа күрә рәхмәтем зур ул остазга. Әтием Тукайның «Кисекбаш», «Шүрәле», «Су анасы»н, кыскасы, Тукайның әсәрен газетада яки кечкенә китапчыкларда басылып чыккан саен алып кайта. Эштән бушагач, кичке аштан соң, мин укыйм, өч энем, әти, әни бишәүләп тыңлыйлар. «Шүрәле» шигырен әти һәр көнне укытмый калмагандыр, кичке намазларын да онытты шикелле. Ихлас тыңлый. «Кырлай урманнарын» укыганда, «Аһ!» дип туктата да, сөйләп китә туган ягын, утын кискәннәрен, ял итеп ятканнарын. Сөенә-сөенә сөйли иде.

Бер истәлек. Типография йортында әтиләрнең дуслары Акҗигитов Шәрәфи дигәннәр тора иде. Аларга барган вакытымда аның хатыны миңа бер чәйнек тоттырып: «Бар әле, Гөлсем, Тукай абыеңа чәйнекне биреп чык әле»,– дип үтенде. Хәреф җыя торган биек өстәлләр арасыннан Габдулла абый: «Өммегөлсем сеңел чәй алып менгән миңа!» – дип каршы алды, күземне дә күтәреп карамыйм, күзем идәндәге төрле матур юка кәгазь кисәкләре өстендә (ул вакыт юка төсле кәгазьләргә афишалар басыла иде).

Габдулла абыйның үткер күзләре тиз сиздe булса кирәк, тиз генә идәнгә төшкән, өстәлдә дә яткан төсле кәгазь ленталарны төрде дә: «Мә, сеңлем, чәчәкләр ясарсың!» – ди. Сөенүемнең иге-чиге юк, шул матур ленталарны кочаклап, җилтерәп чыгып киттем. Матурлыкка шул зур этәргеч көч булды шикелле: бөтен гомерем буена матур төсләр ярattым…»[2]

Мондый истәлекләр Тукайның гадәти көнкүрештәге халәтен, үзенә, кешеләргә мөнәсәбәтен аңларга, халыкчанлыгына төшенергә ярдәм итә.

Тукайның җәсәден кабергә төшерү вакытын сурәтләгән фотосурәт М. Рәхимкулова коллекциясе аркылы керде. Ул безнең даими экспозициядә торды. Артында «Карточку я взял из домашнего альбома Нурмухамеда Абдусабирова в 1936 г. 25|XII, во время поездки в Хорезм», дип имза куелган, кемнеке икәнлеге аңлаешлы түгел. Аерым кешеләр кулында сакланып калган кайбер кызыклы гына әйберләргә дә тап булабыз. Мәсәлән, Тукай вафатыннан соң, сәүдәгәрләр аның сурәтен сабын, конфет кәгазьләрендә куллана башлыйлар, шәхси туплама аша кергән «Тукаевская» дигән язулы шундый конфет кәгазе бездә дә саклана. Тагын бер истәлекле фоторәсемне музеебызда эшләүче филология фәннәре кандидаты Ләйсән Кариева тапшырган иде. Аның әнисе Рәшидәнең атасы Әһлиулла Хәлиуллин Тукай белән уйнап үсә, егет чагында да аралашулары билгеле. Әһлиулла скрипкада уйный. Тукай үләр алдыннан

«килсеннәр» дип хәбәр салган кешеләр арасында Әһлиулла да була. Әмма килә алмый, сәүдә эшләре белән Казакъстанда кала. Күрешә алмый калуына гомере буе үкенеп яши. 1944 елның июлендә (сугыш барган чорда!) Татарстан ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих институты Тукайны белүчеләрдән истәлекләр җыю максаты белән язучы һәм галим Мөхәммәт Гали җитәкчелегендә Арча-Әтнә төбәгенә фәнни экспедиция оештыра. Кырлай авылына да киләләр. Габдулланы белгән Кырлай авылы кешеләрен кырдан чакырып кайтарып, җыелып фотога төшәләр. Әһлиулла инде 1937 елда үлгән була, аның урынына энесе Ярулланы утырталар. Кечкенә генә шушы сурәттә никадәр тарих!

Документаль материаллардан халык язучысы Сибгат ага Хәкимнең тулы архивындагы (4 меңнән артык сакл. бер.) Тукайга багышланган кулъязмалары, шигырь блокнотлары, төрле елларда төрле шәһәр-авылларда (Түбән Кама, Әлмәт, Казан, Кырлай) оештырылган шигырь бәйрәмнәрендә язучылар белән төшкән фотосурәтләре аерым урын алып тора.

Инде бер гасырдан артык, шагыйрьнең исән чагыннан алып бүгенге көнгә кадәр рәссамнар Г. Тукай образын сынландыралар, аның поэзиясенең сихри гүзәллеген, фәлсәфи эчтәлеген ачарга, бөек шагыйрьнең уй-фикер дөньясын, рухи галәмен тудырырга омтылалар. Музей фондларында саклanучы сынлы сәнгать, графика һәм скульптура әсәрләре арасында Б. Урманченың «Печән базары»; «Шүрәле» поэмасына иллюстрацияләре (1979, 1980–1984); Р. Вахитовның Г. Тукай портреты (1970 еллар); А. Абызгилдинның «Тукай төше», «Багышлау. Тукайга, Кол Галигә, Дәрдмәндкә» (2006); Р. Килдебәковның «Шигырь дәфтәреннән» (1993); Н. Әлмиевнең «Шүрәле» поэмасына офортлар сериясе (1994); И. Әхмәдиевнең «Тукай турында сюита» (2009); «Тәфтиләү», «Моңлы сазым» әсәрләре бар.

А. Родионов, З. Гыймаев, Р. Заһидуллин, А. Хисамов һ.б.ның реалистик планда иҗат ителгән нәкышьләре Г. Тукайның туган якларын – Казан арты урманнарын, тын күлләрен, чишмәләрен, болын-кырларын, үз тормышы белән яшәүче авылларын, аның кешеләрен сурәтли. Шагыйрьнең «Казан чоры» белән борынгы калабызның иске тын почмакларын, ишегалларын, шөһрәтле Печән базарын, «Болгар» һәм «Амур» номерларын гәүдәләндергән Т. Зуева, А. Тимергалина, Р. Гыйләҗев әсәрләре таныштыра. В. Аршиновның «Тукайны укыганда» дип аталган графика сериясе, И. Башмаковның тимермәгъдәннән эшләнгән скульптура композицияләре Тукайның тормышын, иҗатын, аның катлаулы һәм халык язмышыннан аерылгысыз гали дөньясын аңларга үзенчә этәргеч бирә.

«Татар әдәбияты исемнәр-утраулардан тора. Син аларга әллә ничә тапкыр якынаясың, һаман серле алар. Тукай – ачылып бетмәгән аерым утрау», – дип язды Сибгат ага Хәким. Чыннан да шулай. Тукайны һәр буын үзенчә ача. Һәркемнең үз Тукае була дип тә әйтер идем мин, чөнки әле үзе исән вакытта ук халык

үзенеке дип таныган Тукай еллар узган саен яңа сыйфатлары, әлегәчә күренми калган яңа төсмерләре белән ачыла бара. Аны һәр укучы, һәр иҗат кешесе, һәр галим үзенчә күрә, үзенчә тоя. Аның олы исемен, бай мирасын, гали җисемен буыннан-буынга җиткерүдә музейларның роле әйтеп бетергесез зур.

**Сведения об авторе:** Халиуллина Рамзия Индусовна, ведущий методист Музейного комплекса города Казани, e-mail: xaliullina61@mail.ru.

**Аннотация.** Статья посвящена воспоминаниям, связанным с личностью великого татарского поэта Габдуллы Тукая (1886–1913), хранящимся в Музейном комплексе города Казани (бывший Музей национальной культуры НКЦ «Казань»).

**Ключевые слова:** Г. Тукай, поэт, музей, родословная, рукописи, воспоминания.

**Abstract.** The article is devoted to the memories associated with the personality of the great Tatar poet Gabdulla Tukay (1886–1913), stored in the Museum Complex of the city of Kazan (the former Museum of National Culture of the National Cultural Center «Kazan»).

**Key words:** G. Tukay, poet, museum, genealogy, manuscripts, memoirs.

## ИСТОЧНИКИ И ЛИТЕРАТУРА

1 Хәсәнова Г. Тукай турында исемдә калганнардан. Кулъязма. 1980 еллар ахыры (4 б.) // Казан шәһәре музей комплексы фондлары. М. Рәхимкулова архивыннан. КП-12917/84, 1 б.

2 Хәсәнова Г. Минем тормыш юлым. Кулъязма. 1969 ел, декабрь (35 б.) // Казан шәһәре музей комплексы фондлары. М. Рәхимкулова архивыннан. КП-12917/85, 4–9 б.